КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 1 сентябрь г.Казань № 651

Терлекләрнең (авыл хуҗалыгы, йорт, зоопарк һәм башка хайваннарны да кертеп), кыйммәтле мехлы җәнлекләрнең, кошларның, балыкларның һәм бал кортларының йогышлы һәм башка авыруларын кисәтү һәм бетерү чараларын үткәрү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын, Теркәп җибәрелә торган ветеринария документларын рәсмиләштерү һәм бирү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын, Кешеләр һәм хайваннар өчен уртак авырулардан һәм азык-төлек белән агуланулардан халыкны саклау чараларын уздыру буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Терлекләрнең (авыл хуҗалыгы, йорт, зоопарк һәм башка хайваннарны да кертеп), кыйммәтле мехлы җәнлекләрнең, кошларның, балыкларның һәм бал кортларының йогышлы һәм башка авыруларын кисәтү һәм бетерү чараларын үткәрү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын;

Теркәп җибәрелә торган ветеринария документларын рәсмиләштерү һәм бирү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын;

Кешеләр һәм хайваннар өчен уртак авырулардан һәм азык-төлек белән агуланулардан халыкны саклау чараларын уздыру буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин